# КАРАР

**12 февраль, 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында уздырылган «Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Яңа Чәбья т. п. гражданнар җыенының 2020 елның 05 декабрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 22 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Яңа Чәбья т. п. гражданнар җыенының 2020 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме?

- 1 пунктта «2100 сум» сүзләрен «4600 сум» сүзләренә алмаштырырга»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 38 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 20 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: **«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Яңа Чәбья т. п. гражданнар җыенының 2020 елның 13**

**ноябрендәге 1 номерлы** карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме?

- 1 пунктта «2100 сум» сүзләрен «4600 сум» сүзләренә алмаштырырга»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т. А. Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710